ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Закон Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон), «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон), Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыру мәсьәләләрен хокукый җайга сала.»;

2) 5 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда һәм «Россия Федерациясе

субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасында җирле үзидарә оештыру мәсьәләләрен хокукый җайга салу, шул исәптән:»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының хокукларын, бурычларын һәм җаваплылыгын хокукый җайга салу.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан муниципаль берәмлекләргә һәм җирле үзидарә органнарына карата башкару-күрсәтү һәм контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыру бары тик Россия Федерациясе Конституциясендә, федераль конституциячел законнарда, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда, башка федераль законнарда һәм шулар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә генә рөхсәт ителә.»;

3) 19 статьяның 1 өлешендә «Федераль закон» сүзләреннән соң «һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләрен өстәргә;

4) 24 статьяның 8 өлешендә «Федераль законда» сүзләреннән соң «һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда» сүзләрен өстәргә;

5) 26 статьяның 6 өлешендә «Федераль законда» сүзләреннән соң «һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ 104-ТРЗ